МИНИСТЕРСТВО
ЗЕМЕЛЬНЫХ И
ИМУЩЕСТВЕННЫХ
ОТНОШЕНИЙ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ
МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ
МИНИСТРЛЫГЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

**06.03.2017** **г. Казань** **№ 86-пр**

**Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) конкурс үткәрү турында нигезләмәне раслау хакында**

«Россия Федерациясенең дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законга, “Россия Федерациясендә дәүләт граждан хезмәте вакантлы вазыйфасын биләүгә карата конкурс үткәрү турында” 1 февраль, 2005 ел, № 112 Россия Федерациясе Президенты Указы, «Татарстан Республикасында дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законына нигезләнеп, Татарстан Республикасында дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү өчен кандидатларны сыйфатлы сайлау һәм Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында нәтиҗәле кадрлар резервы булдыру максатыннан боерам:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында (алга таба – Министрлык) дәүләт граждан хезмәте вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) конкурс үткәрү турында беркетелгән нигезләмәне расларга.

2. Министрлыкның кадрлар бүлегенә түбәндәгеләрне йөкләргә:

Министрлыкта граждан хезмәте вакантлы вазыйфасына кандидатларның профессиональ дәрәҗәсен (кадрлар резервына кертү), аларның бу вазыйфа өчен квалификацион таләпләргә туры килүен даими бәяләү буенча Министрлыкның Конкурс комиссиясе эшен тәэмин итү;

Министрлыкта дәүләт граждан хезмәте вакантлы вазыйфасын биләүгә карата (кадрлар резервына кертелү) конкурс үткәрелү һәм аның нәтиҗәләре турында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәрендәге Министрлыкның рәсми сайтында һәм дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмати системасында мәгълүмат урнаштыру.

3. Финанслар һәм дәүләт заказы бүлегенә, Министрлык аппаратын тотуга каралган бюджет чаралары кысаларында, Министрлыкта граждан хезмәте вакантлы вазыйфасын биләүгә карата (кадрлар резервына кертелү) конкурс үткәрелү белән бәйле, шул исәптән, бәйсез экспертлар хезмәтен түләүгә тотылган чыгымнарны да финанслауны тәэмин итәргә.

4. «Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вакантлы вазыйфасын биләүгә карата конкурс турында» 30.06.2014, № 311-пр Министрлык боерыгын көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

**Министр** **А.К.Хамаев**

Татарстан Республикасы
Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының
06.03.2017 № 86-пр
карары белән расланды

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫНДА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ ГРАЖДАН ХЕЗМӘТЕ ВАКАНТЛЫ ВАЗЫЙФАСЫН БИЛӘҮГӘ КАРАТА (КАДРЛАР РЕЗЕРВЫНА КЕРТҮ) КОНКУРС ҮТКӘРҮ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелү) конкурс (алга таба – конкурс) үткәрүнең тәртибен, шартларын һәм методикасын билгели.

Конкурс Россия Федерациясе гражданнарының Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенә (алга таба – граждан хезмәте) тигез дәрәҗәдә үтеп керә алуы буенча конституциячел хокукын, шулай ук, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең (алга таба - граждан хезмәткәрләре) конкурс нигезендә вазыйфаи үсү хокукын тәэмин итә.

1.2. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында (алга таба – Министрлык) Конкурс «Россия Федерациясенең дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 64 статьялары нигезендә, “Россия Федерациясендә дәүләт граждан хезмәте вакантлы вазыйфасын биләүгә карата конкурс үткәрү турында” 1 февраль, 2005 ел, 112 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указына, «Татарстан Республикасында дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законына, “Татарстан Республикасында дәүләт граждан хезмәтенә кадрлар резервы турында нигезләмәне раслау турында” 2011 елның 14 мартындагы УП-127 номерлы Татарстан Республикасы Президеныт Указына нигезләнеп үткәрелә.

Конкурс Министрлыкта граждан хезмәте вакантлы вазыйфасына дәгъва итүчеләрнең һөнәри дәрәҗәсен (кадрлар резервының граждан хезмәте вазыйфасы), аларның бу вазыйфа өчен квалификация таләпләренә туры килүен бәяләүдән гыйбарәт

1.3. Министрлыкта граждан хезмәте вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү турында Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре

министры (алга таба – министр) карары, граждан хезмәте вакантлы вазыйфасы булган структур бүлекчә җитәкчесенең Министрлыкның кадрлар бүлеге белән килештерелгән һәм дәлилле язмача мөрәҗәгате нигезендә игълан ителә (әлеге Нигезләмәгә 1нче кушымта).

Министрлыкның кадрлар резервына кертелүгә конкурс Министрлыкның кадрлар бүлеге тарафыннан Министрлыкның граждан хезмәте вакантлы вазыйфаларын биләүдә белгечләргә мөмкин булган ихтыяҗ ихтималын һәм Министрлыкта булган кадрлар резервын ел саен бәяләү нәтиҗәләре буенча оештырыла.

Министрлыкның кадрлар резервына кертелүгә конкурс Министрлыкның конкурс комиссиясе тарафыннан әлеге Нигезләмәдә каралган тәртиптә үткәрелә.

1.4. Министрлыкта граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә конкурс түбәндәге очракларда үткәрелми:

билгеле бер чорга биләнә торган "җитәкчеләр" һәм "ярдәмчеләр (киңәшчеләр)" категориясендәге граждан хезмәте вазыйфасы вәкаләтләрен биләү өчен билгеләгәндә;

билгеләү һәм бушату Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан башкарылучы "җитәкчеләр" категориясендәге граждан хезмәте вазыйфасына билгеләгәндә;

вакытлы хезмәт контрактын төзегәндә;

«Россия Федерациясенең дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясының 2 өлешендә, 31 статьясының 1 өлешендә һәм 60.1 статьясының 9 өлешендә каралган очракларда граждан хезмәткәрен дәүләт граждан хезмәтенең бүтән вазыйфасына билгеләгәндә;

граждан хезмәтендә кадрлар резервына кертелгән граждан хезмәткәрен (гражданны) граждан хезмәте вазыйфасына билгеләгәндә.

1.5. Министрлыкта граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә конкурс түбәндәге очракларда үткәрелми:

алар буенча вазыйфаи вәкаләтләрне үтәү дәүләт серен тәшкил итә торган белешмәләрдән файдалануга бәйле булган, Министрлык боерыгы белән раслана торган вазыйфалар исемлеге буенча билгеләгәндә;

министр карары буенча, граждан хезмәтенең кече вазыйфалары төркеменә карый торган граждан хезмәте вазыйфаларына билгеләгәндә.

1.6. Конкурс түбәндәге максатларда үткәрелә:

сәләтләре һәм һөнәри әзерлеге нигезендә граждан хезмәтенә тигез дәрәҗәдә үтеп керүдә Россия Федерациясе гражданнарының конституциячел хокукларын, шулай ук дәүләт граждан хезмәткәрләренең конкурс нигезендә вазыйфада үсү хокукларын тәэмин итү;

граждан хезмәте вакантлы вазыйфасын биләү буенча аеруча туры килә торган кандидатларны Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән таләпләргә җавап бирә торган һәм конкурста катнашуга кертелгән кандидатларның гомуми саны арасыннан сайлап алу;

граждан хезмәте вазыйфаларын биләү өчен Министрлыкның кадрлар резервын формалаштыру.

1.7. Конкурс үткәргәндә хәл ителә торган мәсьәләләр:

барлык кандидатларга алар тарафыннан конкурс биремнәре һәм процедуралары үтәлгәндә тигез шартлар тәэмин итү;

граждан хезмәте культурасы, һөнәри компетентлык һәм шәхси-эшлекле сыйфатларга туры килгән критерийләр нигезендә кандидатларны бәяләү;

конкурста катнашучылар арасыннан, конкурс процедуралары барышында алынган объектив һәм нигезле күрсәткечләрне чагыштыру юлы белән, Министрлыкта граждан хезмәте вакантлы вазыйфалары (кадрлар резервының граждан хезмәте вазыйфалары) таләпләренә җавап бирә торган затларны ачыклау.

## II. Конкурс комиссиясен формалаштыру һәм аның эшләү тәртибе

2.1. “Россия Федерациясендә дәүләт граждан хезмәте вакантлы вазыйфасын биләүгә карата конкурс үткәрү турында” 1 февраль, 2005 ел, 112 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указына нигезләнеп, Министрлыкта конкурсны үткәрү өчен Министрлык боерыгы белән даими нигездә эшләүче конкурс комиссиясе төзелә. Комиссия составына кергән вазыйфаи затларның шәхси составы үзгәргән очракта Министрлык боерыгы нигезендә тиешле үзгәрешләр кертелә.

2.2. Конкурс комиссиясе рәистән, рәис урынбасарыннан, сәркатиптән һәм комиссия әгъзаларыннан тора.

2.3. Конкурс комиссиясе эшчәнлегенә белән комиссия рәисе җитәкчелек итә. Комиссия рәисе булмаганда аның хокукларын һәм бурычларын конкурс комиссиясе рәисе урынбасары башкара.

Конкурс комиссиясенең сәркатибе конкурс комиссиясенең эшен тәэмин итә (гаризаларны кабул итү, теркәү, эшләрне формалаштыру, конкурста катнашучыларны исәпкә алу журналын тутыру, конкурс комиссиясе утырышлары карарларын рәсмиләштерү һ.б.).

2.4. Министрлыкның конкурс комиссиясе составына министр урынбасарлары һәм (яисә) министрның вәкаләтле граждан хезмәткәрләре ( шул исәптән, кадрлар бүлегеннән, юридик идрәдән, конкурс үткәрелә торган структур бүлекчәдән) Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты вәкиле, Министрлык каршындагы Иҗтимагый совет вәкилләре, шулай ук Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт

хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан Министрлык запросы буенча бәйсез экспертлар – граждан хезмәтенә бәйле мәсьәләләр буенча белгечләр рәвешендә экспертларның персональ белешмәләрен күрсәтмичә чакыртыла торган фәнни, мәгариф һәм бүтән оешмаларның вәкилләре керә.

Конкурс комиссиясе составына кертү өчен Министрлык карамагындагы иҗтимагый совет вәкилләре кандидатуралары әлеге совет тарафыннан министр запросы буенча тәкъдим ителә.

Иҗтимагый совет әгъзаларының һәм бәйсез экспертларның гомуми саны конкурс комиссиясендәге барлык әгъзалар санының кимендә дүрттән бер өлешен тәшкил итәргә тиеш.

2.5. Вазыйфаи вәкаләтләрне үтәү дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрдән файдалануга бәйле булган граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрелгәндә конкурс комиссиясенең составы Россия Федерациясенең дәүләт сере турындагы законнары нигезләмәләрен исәпкә алып формалаштырыла.

2.6. Конкурс комиссиясенең составы конкурс комиссиясе тарафыннан кабул ителә торган карарларга йогынты ясый алырдай мәнфәгатьләр каршылыгы килеп чыгу мөмкинлеге калмаслык итеп төзелә.

2.7. Конкурс комиссиясе утырышы граждан хезмәте вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервының граждан хезмәте вазыйфаларын) кимендә ике кандидат булганда үткәрелә һәм, әгәр дә анда аның әгъзалары саныннан кимендә өчтән ике өлеше катнашса, тулы хокуклы булып санала. Конкурс комиссиясе утырышын бары тик комиссиянең граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче әгъзалары составында гына үткәрү рөхсәт ителми.

2.8. Конкурс комиссиясе түбәндәге карарларны кабул итә:

конкурс шартларын билгеләүче документларны, конкурсны үткәрү өчен кирәкле методик һәм башка материалларны раслый;

граждан хезмәте вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) дәгъва итүче гражданнарга (граждан хезмәткәрләренә) конкурс шартлары турында мәгълүмат һәм консультация бирә;

кандидатлардан алынган запрослар буенча конкурс документациясен бирә;

граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) дәгъва итүче кандидатлар тапшырган документларны тикшергәннән соң, конкурс комиссиясе конкурсның икенче этабына үткәрелгән кандидатлар исемлеген раслый;

кандидатларның билгеләнгән таләпләргә туры килүен бәяли;

конкурска нәтиҗә ясау, кандидатны конкурс җиңүчесе итеп тану турында карар кабул итә, аны Министрлыкның кадрлар резервына кертергә тәкъдим итә.

2.9. Конкурсны үткәрү нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе карары ачык тавыш бирү нигезендә аның утырышта катнашкан әгъзалары тавышларының гади

күпчелеге белән кабул ителә. Тавыш биргәндә конкурс комиссиясе әгъзалары фикере «риза» яки «каршы» сүзләре белән генә чагыла. Тавышлар тигез булган очракта, конкурс комиссиясе рәисенең тавышы хәлиткеч була. Конкурс комиссиясенең теләсә кайсы әгъзасы кабул ителгән карар белән килешмәгән очракта үз фикерен белдерә ала, ул конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсенә языла һәм конкурс комиссиясенең әлеге әгъзасы имзасы белән куела.

2.10. Конкурс комиссиясе карары кандидат югында кабул ителә һәм аны Министрлыкта граждан хезмәте вакант вазыйфасына билгеләү (үзенең рөхсәте белән кадрлар резервына кертелү) яисә мондый билгеләүдән баш тарту өчен нигез булып тора.

2.11. Конкурс комиссиянең тавыш бирү нәтиҗәләре конкурс комиссиясе беркетмәсе белән рәсмиләштерелә, анда рәис, рәис урынбасары, сәркатип һәм конкурс комиссиясе утырышында катнашкан конкурс комиссиясе әгъзалары кул куя. Конкурс комиссиясе беренче тапкыр граждан хезмәте вазыйфасына билгеләнгән гражданин өчен, яисә граждан хезмәткәрен Министрлыкның граждан хезмәтенең бер төркеме яки категориясеннән икенчесенә күчергәндә сынау срогының озынлыгын турында киңәш бирә ала.

2.12. Конкурсны һәм конкурс комиссиясенең эшен оештыру һәм үткәрүне тәэмин итүне Министрлыкның кадрлар бүлеге тормышка ашыра.

## III. Конкурста катнашучылар

3.1. Министрлыкта граждан хезмәте вакантлы вазыйфасын биләү (кадрлар резервына кертелү) буенча кандидатларга карата квалификация таләпләренә җавап бирә торган һәм шушы Нигезләмәнең 3.8 пунктында каралган чорда шушы Нигезләмәнең 3.4 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырган гражданнар конкурста катнашуга кертелә.

3.2 Министрлыкта граждан хезмәте вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) кандидатларга таләпләр (әлеге Нигезләмәгә 3 нче кушымта) Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәте турындагы законнары нигезендә билгеләнде.

3.3. Россия Федерациясенең конкурста катнашырга теләк белдергән гражданы Министрлыкка түбәндәгеләрне тапшыра:

а) шәхси гариза (әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымта);

б) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2005 елның 26 маендагы № 667-р карары белән расланган формада үз кулы белән тутырылган һәм имзаланган анкета, фотосын (4х6 см, почмаксыз) теркәп;

в) паспортның яки аны алмаштыра торган документның (тиешле документ конкурска килгәч шәхсән күрсәтелә) күчермәсе;

г) кирәкле һөнәри белемне, квалификацияне һәм эш стажын раслый торган документлар:

хезмәт кенәгәсенең (хезмәт (эш) эшчәнлеге беренче мәртәбә гамәлгә ашырыла торган очраклар искәрмә булып тора) нотариаль яктан яки хезмәт итү (эш) урыны буенча кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган күчермәсе яки гражданның эшкә бәйле (хезмәт) эшчәнлеген раслый торган башка документлар;

белем алу турында һәм квалификация турындагы документларның күчермәләре, шулай ук, үз ихтыяры буенча, өстәмә һөнәри белем алу нәтиҗәләре буенча квалификация күтәрүне яки бирелүне раслый торган документларның, фәнни дәрәҗә, фәнни исем бирелү турындагы документларның нотариаль яктан яки эш (хезмәт итү) урыны буенча кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган күчермәләре;

д) гражданда граждан хезмәтенә керүгә яки аны үтүгә комачаулый торган чирләрнең булмавы турында документ (Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының 2009 елның 14 декабрендәге 984н номерлы боерыгы белән расланган 001-ГС/у исәп формасы);

е) «Россия Федерациясенең дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законга, башка федераль законнарда, Россия Федерациясе Президенты указларында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларында каралган башка документлар.

3.4. Министрлыкның конкурста катнашу теләген белдергән граждан хезмәткәре министр исеменә гариза тапшыра.

3.5. Башка дәүләт органында вазыйфа биләүче, конкурста катнашу теләген белдергән граждан хезмәткәре Министрлыкка министр исеменә язылган шәхси гариза һәм үз куллары белән тутырылган, имзаланган һәм граждан хезмәткәре граждан хезмәте вазыйфасын үтә торган дәүләт органының кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2005 елның 26 маендагы 667-р номерлы карары белән расланган рәвештә анкета тапшыра, фотосын (4x6 см, почмаксыз) теркәп.

3.6. Гражданның (граждан хезмәткәренең) ризалыгы белән аңа дәүләт серен яки закон белән саклана торган бүтән серне тәшкил итә торган белешмәләрдән файдалануга рөхсәт бирү процедурасы рәсмиләштерелә, әгәр дә граждан (граждан хезмәткәре) биләүгә дәгъва кыла торган граждан хезмәте вазыйфасы буенча вазыйфаи бурычларны башкару мондый белешмәләрдән файдалануга бәйле булса.

Граждан тарафыннан министр исеменә тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеге тикшерелергә тиешле.

Граждан хезмәткәре тарафыннан тапшырылган белешмәләрнең дөреслеге, аның Министрлыкның граждан хезмәте вазыйфаларының югары төркеменә

кергән вакантлы граждан хезмәте вазыйфаларын биләү өчен конкурска катнашкан очрагында гына тикшерелә.

3.7. Конкурста катнашу өчен документлар кандидатлар тарафыннан конкурс комиссияләренә конкурсны үткәрү турында мәгълүмати хәбәр "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәрендә Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең рәсми порталында Министрлыкның рәсми сайтында һәм дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмати системасында урнаштырылганнан соң 21 көн эчендә тапшырыла.

3.8. Документларны үз вакытында тапшырмау, аларны тулы күләмдә тапшырмау яки рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшыру гражданнан аларны кабул итүдән баш тартуга нигез булып тора.

Документларны үз вакытында тапшырмау, аларны тулы күләмдә тапшырмау яки рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшыруның җитди сәбәпләре булса, министр аларны кабул итү вакытын күчерергә хокуклы.

## IV. Конкурсларны үткәрү методикасы

4.1. Конкурсны үткәргәндә кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү методларына таянган, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килми торган конкурс биремнәре һәм процедуралары кулланыла.

4.2. Кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү критерийләре Министрлыкта граждан хезмәте вазыйфаларына куела торган квалификация таләпләре нигезендә эшләнде.

Конкурс үткәрелә торган вазыйфаларның төркеменә һәм категориясенә карап, конкурста катнашучыларны бәяләү критерийләре һәм сайланган бәяләү ысуллары үзгәртелергә мөмкин.

Конкурста катнашучыларны бәяләү критерийларының якынча исемлеге һәм кыскача тасвирламасы әлеге Нигезләмәнең 4 нче кушымтасында китерелгән.

4.3. Кандидатларны чагыштыру һәм сайлап алу алар тарафыннан конкурс биремнәрен үтәү һәм конкурс процедураларын үтү нәтиҗәләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

4.4. Конкурс ике этапта үткәрелә.

4.4.1. Беренче этапта Министрлыкның кадрлар бүлеге түбәндәгеләрне оештыра:

конкурсны үткәрү турында мәгълүмат әзерли һәм "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәрендә Татарстан Республикасы Хөкүмәте рәсми порталындагы Министрлыкның рәсми сайтында һәм дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмати системасында урнаштыра, әлеге мәгълүмат түбәндәгеләрне үз

эченә ала: граждан хезмәте вакант вазыйфасының (кадрлар резервындагы граждан хезмәте вазыйфасының) аталышы, бу вазыйфаны биләү өчен квалификация таләпләре, граждан хезмәтен үтү шартлары, документларны кабул итү урыны һәм вакыты, күрсәтелгән документларны кабул итү срогы, конкурсны үткәрүнең күзалланган вакыты, аның үткәрелү урыны һәм тәртибе, башка мәгълүмати материаллар. Конкурста катнашу өчен документлар кабул итү турындагы игълан һәм конкурс турындагы мәгълүмат вакытлы матбугатта да бастырыла ала;

граждан (граждан хезмәткәре) тарафыннан тапшырылган документларны тикшерә:

гражданның (граждан хезмәткәренең) квалификация таләпләренә туры килүен тикшерә (һөнәри белем дәрәҗәсе, граждан хезмәте (бүтән төрле граждан хезмәтенең) стажы яки белгечлеге буенча эшләү стажы (тәҗрибәсе), әзерлеккә юнәлтелүе, вазыйфаи бурычларны үтәү өчен кирәкле булган һөнәри белемнәре һәм күнекмәләре).

конкурсның беренче этабы документлар кабул ителү турында игълан урнаштырылган көнне башлана һәм 21 көннән дә иртәрәк тәмамланмый.

4.4.2. Тикшерү барышында федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының бүтән норматив-хокукый актлары нигезендә гражданның граждан хезмәтенә керүенә каршы килә торган шартлар ачыкланган очракта, аңа министр тарафыннан конкурста катнаштырудан баш тартуның сәбәпләре хакында язмача хәбәр ителә.

4.4.3. Конкурста катнашуга кертелмәгән, Министрлыкта вакант вазыйфаны биләү өчен дәгъва кылучы бу карарны Россия Федерациясе законнары нигезендә шикаять кылырга хокуклы.

4.4.4. Министрлыкта граждан хезмәтенең бер вакантлы вазыйфасына (кадрлар резервындагы граждан хезмәте вазыйфасына) билгеләнгән квалификация таләпләренә җавап бирә торган кимендә ике кандидат булуы конкурсның беренче этабын төгәлләү шарты булып тора, бу кандидатларны алга таба сайлау мөмкинлеген тәэмин итә.

Кандидатлар булмаганда яки вазыйфага карата квалификация таләпләренә җавап бирә торган бары тик бер генә кандидат булган очракта, конкурс узмаган дип танылa. Бу очракта бердәнбер кандидатка таләп ителүче кандидатлар саны булмауга бәйле рәвештә конкурс комиссиясе тарафыннан конкурсның узмаган дип танылуы хакында язмача хәбәр ителә.

4.4.5. Беренче этапның нәтиҗәсе булып конкурс комиссиясенең куелган таләпләргә күбрәк туры килүче һәм алга таба конкурста катнашырга киңәш ителүче кандидатлар исемлеге төзелү турында карары тора, карар конкурс комиссиясе рәисе тарафыннан раслана.

4.4.6. Конкурсның беренче этабы тәмамлангач, министр конкурсның икенче этабын үткәрү датасы, вакыты һәм урыны турында карар кабул иткәннән соң, конкурс комиссиясе конкурсның икенче этабын үткәрә.

Министрлыкның кадрлар бүлеге конкурсның икенче этабы башланырга кимендә 15 көннән соңга калмыйча конкурста катнашуга кертелгән кандидатларга аның үткәрелү датасы, вакыты һәм урыны турында хәбәр җибәрә.

4.4.7. Конкурсның икенче этабында түбәндәгеләр гамәлгә ашырыла:

а) конкурс комиссиясе тарафыннан кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү;

б) Министрлыкта граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) конкурста җиңүчене билгеләү турында министр карарын кабул итү.

4.4.8. Конкурсны үткәргәндә конкурс комиссиясе кандидатларны белеме, граждан хезмәтен яки бүтән дәүләт хезмәтен үтәү, башка хезмәт эшчәнлеген башкару турында алар тарафыннан тапшырылган документлар нигезендә, шулай ук кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү буенча Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килми торган ысуллардан файдаланып, шул исәптән Министрлыкта граждан хезмәте вакант вазыйфасы (кадрлар резервындагы граждан хезмәте вазыйфасы) буенча вазыйфаи бурычларны үтәүгә бәйле булган мәсьәләләрдә тест һәм шәхси әңгәмә уздыру юлы белән һәм башка төрле конкурс процедуралары нигезендә бәяли.

4.4.9. Министрлыкта граждан хезмәтенең билгеле бер вакантлы вазыйфасына (кадрлар резервындагы граждан хезмәте вазыйфасына) кандидатларга тест уздыру Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаментының 2016 елның 11 гыйнварындагы 1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарга тест уздыру методикасы нигезендә гамәлгә ашырыла (алга таба - 11.01.2016 № 1 Карар).

4.4.10. 11.01.2016 № 1 Карарга нигезләнеп тест уздырылудан тыш, кандидатларны граждан хезмәтенең билгеле бер вакант вазыйфасына (кадрлар резервындагы граждан хезмәте вазыйфасына) вакант вазыйфа булган структур бүлекчә алдан әзерләгән теоретик сорауларның бердәм исемлеге буенча да тест уздырыла (кадрлар резервындагы граждан хезмәте вазыйфасы билгеләнә).

Тест Министрлыкта граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи бурычларын башкару өчен кирәкле профессиональ белем һәм күнекмәләр базасында төзелә.

Граждан хезмәтенең билгеле бер вакант вазыйфасына (кадрлар резервындагы граждан хезмәте вазыйфасына) кандидатларга тест буенча язмача җавап әзерләү өчен бер үк төрле вакыт бирелә.

Тест дөрес җаваплар саны буенча бәяләнә. Дөрес булмаган җаваплар саны 25 проценттан да артык була алмый. Тестта уннан да ким булмаган һәм утыздан артмаган сорау булырга тиеш.

4.4.11. Тест үткән кандидатлар белән шәхси әңгәмәләр конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан үткәрелә.

Шәхси әңгәмә кандидатларның булачак һөнәри хезмәт итү эшчәнлеге темасы буенча конкурс комиссиясе әгъзаларының сорауларына бирелә торган җавапларыннан гыйбарәт. Әңгәмә барышында конкурс комиссиясе кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын граждан хезмәте вазыйфасына һәм әлеге вазыйфа буенча вазыйфаи регламентның бүтән нигезләмәләренә карата тиешле квалификация таләпләреннән чыгып, шулай ук әлеге Нигезләмәнең һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәте турындагы законнарында билгеләнгән башка нигезләмәләренә таянып бәяли.

Телдән бирелгән җаваплар нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе вакантлы вазыйфага кандидатны бәяли һәм сайлый.

4.5. Кандидатлар тарафыннан алынган тавышларның саны, кандидатлар шундагы вазыйфага дәгъва кыла торган структур бүлекчә җитәкчесенең фикере Министрлыкта граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) кандидат турында карар кабул итү һәм конкурска йомгак ясау өчен нигез булып торалар.

«Риза» дигән тавышны күбрәк җыя алган кандидат конкурсның җиңүчесе дип танала.

4.6. Конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсенә кертелгән конкурс комиссиясе карары конкурсның икенче этабы нәтиҗәсе булып һәм шул ук вакытта конкурсның йомгаклау нәтиҗәсе булып тора.

4.7. Конкурс үткәрү нәтиҗәсендә граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләү өчен (кадрлар резервына кертелүгә) квалификацион таләпләргә җавап бирүче кандидатлар ачыкланмаса, министр кабатлап конкурс үткәрү карары кабул итә ала.

4.8. Граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс нәтиҗәләре буенча Министрлыкның конкурста җиңүчене граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасына билгеләү турында боерыгы чыгарыла һәм аның белән хезмәт контракты төзелә. Конкурс комиссиясе граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасы конкурсында җиңмәгән, ләкин һөнәри һәм шәхси сыйфатлары югары бәягә лаек булган кандидатны Министрлыкның кадрлар резервына кертү турында тәкъдим сыйфатында карар кабул итәргә хокуклы.

Кандидат ризалыгы белән, аны граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасы карый торган шул ук төркемдәге граждан хезмәте вазыйфасын биләү буенча кадрлар резервына кертү турында Министрлык боерыгы чыгарыла. Граждан

хезмәткәрен (гражданны) – конкурста җиңүчене кадрлар резервына кертү Министрлык боерыгы белән рәсмиләштерелә һәм граждан хезмәткәренең шәхси эшенә Министрлык боерегының күчермәсе беркетелә.

4.9. Граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелү) кандидат конкурс комиссиясе карарын Россия Федерациясе законнары нигезендә шикаять кылырга хокуклы.

4.10. Конкурс нәтиҗәләре турындагы хәбәрләр конкурс төгәлләнгәннән соң 7 көн эчендә конкурста катнашучыларга язмача рәвештә юллана. Конкурс нәтиҗәләре хакында мәгълүмат аны үткәргәннән соң шул ук күрсәтелгән вакыт эчендә «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәрендә Министрлыкның рәсми сайтында һәм дәүләт хезмәте өлкәсендәге дәүләт мәгълүмати системасында урнаштырыла.

4.11. Граждан хезмәте вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) дәгъва кылган, ләкин конкурста катнашуга кертелмәгән кандидатларның һәм конкурста катнашкан кандидатларның документлары конкурс тәмамланган көннән соң өч ел дәвамында язма гаризалары буенча аларга кайтарып бирелергә мөмкин. Әлеге чор тәмамланганчыга кадәр документлар Дәүләт комитеты архивында саклана, аннан соң юкка чыгарылырга тиеш.

4.12. Конкурста катнашуга бәйле чыгымнар (конкурс үткәрелгән урынга бару һәм кайту, торак бинага түләү, яшәү, элемтә чаралары хезмәтләреннән файдалану һәм башкасы) кандидатлар тарафыннан үз акчалары хисабыннан түләнә.

Татарстан Республикасы Җир һәм
мөлкәт мөнәсәбәтләре
министрлыгында Татарстан
Республикасы дәүләт граждан хезмәте
вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар
резервына кертелүгә) конкурс үткәрү
турында нигезләмәгә
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрына

______________________________________

(инициаллары, фамилия)

Гариза

Сездән Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында
___________________________________________________________________________

(вазыйфаның атылышы)

___________________________________________________________________________

______________________________________________________

(бүлек аталышы)

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелү) конкурс игълан итүегезне сорыйм.

Бу вазыйфаны биләү өчен дәгъва кылучыга карата түбәндәге квалификация таләпләре белдерелә:

белеме - __________________________________________________________

дәүләт хезмәте стажы һәм эш тәҗрибәсе - __________________________

күнекмәләре һәм осталыгы - _____________________________________________________

___________________________________________________________________________

Структур бүлекчә җитәкчесе

_____________          _______________________________

(дата)          (имза, имзаны шәрехләү)

Килештерелгән:
Министр урынбасары

_____________          _______________________________

(дата)          (имза, имзаны шәрехләү)

Татарстан Республикасы Җир һәм
мөлкәт мөнәсәбәтләре
министрлыгында Татарстан
Республикасы дәүләт граждан хезмәте
вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар
резервына кертелүгә) конкурс үткәрү
турында нигезләмәгә
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрына
________________________________________
(инициаллары, фамилия)
(Кемнән) ______________________________________
(фамилия, исем, әтисе исеме(булса)
белеме ____________________________,
________________________________________,
(төре, уку йорты, тәмамлаган елы)
________________________________________
_____________________ адресы буенча яши,
тел. __________________________________,
(эш, өй, мобиль)
e-mail _________________________________

Гариза

Мине Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вакантлы вазыйфасын биләү өчен (кадрлар резервына кертелү) конкурсta катнашырга рөхсәт итүегезне сорыйм.

______________________________________________________________________________
(вазыйфаның атамасы)
______________________________________________________________________________
(структур бүлекчәнең атамасы)

«Россия Федерациясенең дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законы, «Татарстан Республикасында дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы, "Россия Федерациясендә дәүләт граждан хезмәте вакантлы вазыйфасын биләүгә карата конкурс үткәрү турында" 1 февраль, 2005 ел, 112 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы, Россия Федерациясе һәмм Татарстан Республикасында дәүләт граждан хезмәте турында башка норматив хокукый актлар, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) конкурс үткәрү турында нигезләмә, шул исәптән, күрсәтелгән вазыйфага куелган квалификация таләпләре белән таныштым.

Дәүләт сере һәм закон нигезендә сакланулы башка төрле сер булып торган мәгълүматлары белән эш итү мөмкинлеген рәсмиләштерү процедурасы үткәрелүгә ризалык белдерәм.

Конкурс үткәрү датасы һәм урыны турында e-mail аша хәбәр ителүенә яисә күрсәтелгән мобиль телефонга смс-хәбәр җибәрелүгә ризалык бирәм.

Гаризага түбәндәнеләрне терким: (теркәлгән документлар санала).

______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________

| | | |
|---|---|---|
| __________________ | _______________________ | ___________________________ |
| (дата) | (имза) | (имзаны шәрехләү) |

Татарстан Республикасы Җир һәм
мөлкәт мөнәсәбәтләре
министрлыгында Татарстан
Республикасы дәүләт граждан хезмәте
вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар
резервына кертелүгә) конкурс үткәрү
турында нигезләмәгә
3 нче кушымта

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫНДА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ ГРАЖДАН ХЕЗМӘТЕ ВАКАНТЛЫ ВАЗЫЙФАСЫН БИЛӘҮГӘ (КАДРЛАР РЕЗЕРВЫНА КЕРТҮ) КАНДИДАТЛАРГА ТАЛӘПЛӘР

## 1. Гомуми таләпләр

1.1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында (алга таба – Министрлык) Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте (алга таба – граждан хезмәте) вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) конкурста Россия Федерациясенең дәүләт телен белгән һәм Министрлыкта граждан хезмәте вакантлы вазыйфасын биләү өчен Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәте турында законнарга нигезләнеп билгеләнгән квалификацион таләпләргә җавап бирүче 18 яше тулган Россия Федерациясе гражданнары катнаша ала.

Граждан хезмәткәре, конкурс үткәрелгән вакытта нинди вазыйфаны биләвенә карамастан, гомуми нигезләрдә Министрлыкта граждан хезмәте вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) конкурста катнашырга хокуклы.

1.2. Гражданин (граждан хезмәткәре) граждан хезмәте вакантлы вазыйфасын биләү өчен (кадрлар резервына кертелүгә) куелган квалификация таләпләренә туры килмәгәндә, шулай ук дәүләт граждан хезмәтенә керү һәм аны үтү буенча дәүләт граждан хезмәте турында Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән чикләүләр белән бәйле рәвештә конкурска кертелми.

## 2. Квалификацион таләпләр

2.1. Граждан хезмәте вазыйфаларын биләү өчен квалификация таләпләре һөнәри белем дәрәҗәсенә, граждан хезмәте стажына яисә белгечлеге буенча эш стажына, вазыйфаи бурычларын үтәү өчен кирәкле һөнәри белемнәренә һәм

күнекмәләренә карата, шулай ук министрның тиешле карары булганда, белгечлеккә, әзерлек юнәлешенә карата куела.

2.2. Граждан хезмәте вазыйфаларын биләү өчен квалификация таләпләре граждан хезмәте вазыйфаларының категорияләре һәм төрләре, граждан хезмәткәренең һөнәри эшчәнлеге өлкәсе һәм төре нигезендә билгеләнә.

2.3. Һөнәри белем дәрәҗәсенә квалификация таләпләре:

гражданлык хезмәте вазыйфаларының югары һәм баш төркемнәренә керүче “җитәкчеләр”, “ярдәмчеләр (киңәшчеләр)”, “белгечләр” категорияләрендә гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләү өчен белгечлек, магистратура дәрәҗәсеннән ким булмаган югары белем булу тиеш;

гражданлык хезмәте вазыйфаларының әйдәүче төркеменә керүче “җитәкчеләр”, “ярдәмчеләр (киңәшчеләр)” категорияләрендә гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләү өчен, шулай ук гражданлык хезмәте вазыйфаларының әйдәүче төркеменә һәм өлкән төркеменә керүче “белгечләр” категориясендә гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләү өчен, шулай ук, төп һәм әйдәүче төркемнәренә керүче “тәэмин итүче белгечләр” категориясендә гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләү өчен югары белемгә ия булу мәҗбүри;

өлкән һәм кече төркемнәргә керүче “тәэмин итүче белгечләр” категориясендә гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләү өчен һөнәри белемгә ия булу кирәк.

2.4. Гражданлык хезмәте стажына яки белгечлек буенча эш стажына, гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләү өчен кирәкле гражданлык хезмәткәрләренең әзерләнү юнәлешенә түбәндәге квалификация таләпләре билгеләнә:

гражданлык хезмәте вазыйфаларының югары һәм баш төркемнәренә керүче “җитәкчеләр”, “ярдәмчеләр (киңәшчеләр)” гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләү өчен - кимендә өч еллык гражданлык хезмәте стажы яисә белгечлек, әзерләнү юнәлеше буенча кимендә җиде еллык эш стажы;

гражданлык хезмәте вазыйфаларының югары төркеменә керүче “белгечләр” категорияләрендә гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләү өчен - кимендә өч еллык гражданлык хезмәте стажы яисә белгечлек, әзерләнү юнәлеше буенча кимендә биш еллык эш стажы;

гражданлык хезмәте вазыйфаларының төп төркеменә керүче барлык категорияләрендә гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләү өчен - кимендә ике еллык гражданлык хезмәте стажы яисә белгечлек, әзерләнү юнәлеше буенча кимендә өч еллык эш стажы;

гражданлык хезмәте вазыйфаларының әйдәүче төркеменә керүче барлык категорияләрендә гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләү өчен – кимендә бер еллык гражданлык хезмәте стажы яисә белгечлек, әзерләнү юнәлеше буенча кимендә ике еллык эш стажы.

гражданлык хезмәте вазыйфаларының өлкән һәм кече төркемнәренә керүче гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләү өчен гражданлык хезмәте стажына яки белгечлек буенча эш стажына, әзерләнү юнәлешенә карата квалификация таләпләре билгеләнми.

Граждан хезмәте стажын билгеләгәндә тиешле вазыйфаи төркемнәрдә федераль дәүләти граждан хезмәте вазыйфаларында, тиешле вазыйфаи төркемнәрдә хәрби вазыйфаларда һәм башка төр федераль дәүләт хезмәте вазыйфаларында, дәүләт вазыйфаларында, муниципаль вазыйфаларда, муниципаль хезмәт вазыйфаларында, федераль законнарга туры китереп башка вазыйфаларда эшләү стажы да исәпкә алына.

2.5. Эшчәнлек юнәлешенә туры килгән гыйльми дәрәҗәсе булган затларга гражданлык хезмәте вазыйфаларының баш һәм әйдәүче төркеменә керүче «ярдәмчеләр (киңәшчеләр)» категорияләрендә гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләү өчен, гражданлык хезмәте вазыйфаларының баш һәм әйдәүче төркеменә керүче «белгечләр» категориясендә гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләү өчен, дәүләт органы җитәкчесенең карары буенча, әлеге таләпләрнең 2.4 пункты белән билгеләнгән гражданлык хезмәте стажына яки белгечлек буенча эш стажына, әзерләнү юнәлешенә карата квалификация таләпләре исәпкә алынмаска мөмкин.

2.6. Белгеч яки магистр дипломында бик яхшы билгеләре генә булган затлар өчен, диплом алынган беренче өч ел эчендә гражданлык хезмәте стажына яки белгечлек буенча эш стажына, әзерләнү юнәлешенә карата квалификация таләпләре граждан хезмәтендә бер елдан да ким булмаган эш стажы яки белгечлек буенча эш стажы, әзерләнү юнәлеше билгеләнә.

2.7. Вазыйфаи бурычларын башкару өчен кирәкле белем һәм күнекмәләргә квалификация таләпләре граждан хезмәткәренең рәвештә һөнәри хезмәт эшчәнлеге өлкәсе һәм төренә карап, вазыйфаи регламентына бәйле рәвештә билгеләнә. Граждан хезмәте вазыйфасын биләү өчен кирәкле белгечлек һәм әзерләнү юнәлешенә квалификация таләпләре граждан хезмәткәренең вазыйфаи регламенты буларак карала ала.

Татарстан Республикасы Җир һәм
мөлкәт мөнәсәбәтләре
министрлыгында Татарстан
Республикасы дәүләт граждан хезмәте
вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар
резервына кертелүгә) конкурс үткәрү
турында нигезләмәгә
4 нче кушымта

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫНДА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ ГРАЖДАН ХЕЗМӘТЕ ВАКАНТЛЫ ВАЗЫЙФАСЫН БИЛӘҮГӘ (КАДРЛАР РЕЗЕРВЫНА КЕРТҮ) КОНКУРСТА КАТНАШУЧЫЛАРНЫ БӘЯЛӘҮ КРИТЕРИЙЛАРЫ

## 1. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәре культурасына туры килү

1.1. Һөнәри мотивация.

Татарстан Республикасында дәүләт граждан хезмәтендә һөнәри яктан үз-үзеңне танып белүгә омтылу, дәүләт идарәсе өлкәсендә хезмәттә үсүгә исәп тоту.

1.2. Гражданлык позициясе.

Эшчәнлектә җәмәгатьчелеккә һәм дәүләткә хезмәт итү принципларын үтәү, законлылыкны, хезмәт этикасы кагыйдәләрен саклау.

1.3. Һөнәри позиция активлыгы.

Куелган бурычларны хәл иткәндә инициатива күрсәтүгә омтылу; мөмкин булган иң яхшы нәтиҗәгә ирешү өчен җитди тырышлык куярга әзер булу; физик һәм эмоциональ басым шартларында нәтиҗәле эш итә алу сәләте (стрессларга каршы торучанлык).

1.4. Үзлектән үсүгә әзер булу.

Даими рәвештә белемнәреңне, осталыкларыңны һәм күнекмәләреңне камилләштерүгә, белем дәрәҗәсен киңәйтүгә, эргәдәш профессияләр өлкәләрендә белем һәм тәҗрибә туплауга омтылу.

## 2. Дәүләт хезмәткәренең һөнәри компетентлыгы

2.1. Белем алу дәрәҗәсе.

Төп һәм өстәмә һөнәри белемнең дәрәҗәсе, юнәлеше һәм сыйфаты

2.2. Һөнәри тәҗрибә.

Тиешле профессиональ өлкәдәге эшчәнлекнең дәвамлылыгы һәм үзенчәлекләре;

һөнәри эшчәнлектә конкрет нәтиҗәләргә ирешү;

карьера үзенчәлекләре

2.3. Махсус һөнәри белемнәр, осталыклар һәм күнекмәләр.

Тиешле өлкәдә функциональ бурычларны нәтиҗәле үтәргә мөмкинлек бирүче һөнәри белем дәрәҗәсе;

һөнәри эшчәнлекне регламентлаучы Россия Федерациясе законнарын белү;

заманча һөнәри технологияләр белән эш итә белү.

2.4. Гомуми инструменталь күнекмәләр.

Һөнәри эшчәнлекнең гомуми нәтиҗәлелеген арттыручы күнекмәләр белән эш итү дәрәҗәсе (компьютерда эшли белү, гомуми грамоталылык, чит телләр белү һ.б. ш.).

## 3. Граждан хезмәткәренең шәхси-эшлекле сыйфатлары

3.1. Аналитик сәләте.

Мәгълүматны анализлауны һәм структуралаштыруны таләп итүче авыр мәсьәләләрне хәл итәргә мөмкинлек бирүче фикерләү системалылыгы һәм зирәклеге дәрәҗәсе;

яңа, гайре табигый булмаган чишелешләр таба алу сәләте.

3.2. Нәтиҗәле коммуникация күнекмәләре.

Эшлекле аралашу этикасын саклау;

үз фикереңне дәлилле яклый белү һәм оппонентларны ышандыра белү сәләте;

эшлекле сөйләшүләр алып бара алу күнекмәсенә ия булу.

3.3. Җаваплылык.

Карарларны кабул иткәндә нигезлелек һәм мөстәкыйльлек;

нәтиҗәгә ирешкәндә үз өстеңә алган йөкләмәләрне үтәргә әзер булу.

3.4. Оештыру сәләте.

Үз эшчәнлегеңне һәм кул астындагыларның эшчәнлеген дөрес планлаштыру, функцияләрне, вәкаләтләрне һәм җаваплылыкны дөрес бүлү хисабына нәтиҗәләргә ирешә алу.